ГЛАВА МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

**Карар** **Постановление**

№ 145 от « 15 » 09 2023 г.

Район Башлыгының 2015 елның
3 июнендәге 049 нчы карарына
үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында
(07.05.2020 ел, №032; 20.07.2022 ел, № 133; 16.12.2022 ел, № 242 карарлардагы үзгәрешләр белән)

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында» 2010 елның 30 июлендәге № 60-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы, Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына һәм «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 21 июлендәге № 67-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы нигезендә к а р а р б и р ә м:

1. Мамадыш муниципаль районы Башлыгының 2015 елның 3 июнендәге «Мамадыш муниципаль районы җирле үзидарә органнарының административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлары исемлеген билгеләү турында» 049 нчы карары белән расланган административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлегенә административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 2.21 статьясы буенча беркетмәләр төзүне өстәргә (кушымта нигезендә).

2. Әлеге карарны Мамадыш муниципаль районының mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольгә алуны Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе О.Н.Павловка йөкләргә.

Муниципаль район
башлыгы А.П.Иванов

000154

Муниципаль район Башлыгының
«15» 09 2023 ел, №145
карарына кушымта

| статья № | Содержание статьяның | Протоколлар төзү вәкаләтләре йөкләнгән җирле үзидарә органы | Вазифаи затның вазифасы |
|---|---|---|---|
| Ст.2.21 КоАП РТ | Режим (төп әзерлек дәрәҗәсе) кысаларындагы чараларны гамәлгә ашыруны күздә тотучы Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары таләпләрен үтәмәү | муниципаль районның Башкарма комитеты | -Муниципаль район башкарма комитеты җитәкчесенең урынбасары (социаль мәсьәләләр буенча);<br>-Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының хокук эше бүлеге баш белгече (җәмәгать тәртибен саклауны һәм җәмәгать куркынычсызлыгын оештыру буенча)<br>-Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының хокук эше бүлегенең әйдәүче белгече (торак секторда хокук бозуларны профилактикалау һәм индивидуаль профилактик йогынты чараларын куллану буенча инспектор),<br>- Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге җитәкчесе<br>-Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге баш белгече<br>-Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге белгече |